**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Ленино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 18 нче декабре №52-151

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 9.04.2020 № 72-146 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 9.04.2020 №72-146 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советында Муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 15.06.2020 №74-151, 26.03.2021 №9-23, 2.07.2021 №14-35, 31.05.2022 № 25-71, 6.03.2023 № 34-101; 24.08.2023 № 40-117; 8.04.2024 №46-137;24.10.2024 №50-146 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 22 Бүлек 22.2 өлешкә:

1 пунктның «в» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган яисә контрольдә тотылган җирле үзидарә органында ышанычлы яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булырга;»;

4 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен «кайсы сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «, сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.;

8 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен «һәм аның җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 16 бүлеге 16.3 өлешнең унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә

органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы — С.Ю.Питеркина

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЛЕНИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 06-585/14
СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ